КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 22 гыйнвар г.Казань № б-70

Инженер һәм техник кадрларның яңа буынын формалаштыру һәм эшчеләр һөнәрләрен популярлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карары белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмә нигезендә:

1. 2024 елның 1 мартыннан 10 ноябренә кадәр «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының XII еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрергә.

2. Фестивальдә катнашуга заявкалар 2024 елның 1 мартыннан 20 сентябренә кадәр кабул ителә дип билгеләргә.

3. «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының XII еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү графигын (боерыкка теркәлә) расларга.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 22 гыйнвар, б-70 нче
боерыгы белән расланды

«Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының XII еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү графигы

| Турның исеме | Оешмалары катнашырга чакырыла торган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемнәре | Турны уздыру урыны һәм датасы | Гала-концертны уздыру урыны һәм датасы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 нче зона туры | Азнакай, Аксубай, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Зәй, Лениногорск, Яңа Чишмә, Нурлат, Сарман, Спас, Чирмешән, Чистай, Ютазы муниципаль районнары | Әлмәт шәһәре, «Нефтьче» Мәдәният сарае, 2024 елның 4 – 5 октябре (җомга, шимбә) | Әлмәт шәһәре, «Нефтьче» Мәдәният сарае, 2024 елның 5 октябре (шимбә) |
| 2 нче зона туры | Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Тукай муниципаль районнары һәм Яр Чаллы шәһәре | Яр Чаллы шәһәре, «КАМАЗ» Мәдәният сарае 2024 елның 11 – 12 октябре (җомга, шимбә) | Яр Чаллы шәһәре, «КАМАЗ» Мәдәният сарае, 2024 елның 12 октябре (шимбә) |
| 3 нче зона туры | Апас, Арча, Әтнә, Балтач, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Тәтеш, Теләче муниципаль районнары һәм Казан шәһәре | Казан шәһәре, «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, 2024 елның 18 – 19 октябре (җомга, шимбә) | Казан шәһәре, «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, 2024 елның 19 октябре (шимбә) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Финал | Жюри рәисе һәм генераль продюсерның махсус чакыруын алган зона турларында җиңүчеләр | Казан шәһәре, «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, 2024 елның 7 – 8 ноябре (җомга, шимбә) | Казан шәһәре, «Пирамида» мәдәният-күңел ачу комплексы, 2024 елның 10 ноябре (репетиция көне – 2024 елның 9 ноябрендә «Пирамида» мәдәният-күңел ачу комплексында) |